ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

31.01. 2020 ел Баулы шәһәре №18

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 19 апрелендәге 107 номерлы карары белән (2019 елның 10 июнендәге 162 номерлы карары, 2019 елның 24 июлендәге 218 номерлы, 2019 елның 4 сентябрендәге 257 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2029 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 19 апрелендәге 107 номерлы карары белән (2019 елның 10 июнендәге 162 номерлы карары, 2019 елның 24 июлендәге 218 номерлы, 2019 елның 4 сентябрендәге 257 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2нче «муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5 пунктның икенче баганасындаһәм 2.6 пунктының беренче абзацында “тезелешкә рехсәт бирү турында гариза алган кеннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча” сүзләрен төшереп калдырырга;

3нче «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, күпфункцияле үзәкләрнең читтәге эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре» бүлегендә:

3.4.1.пунктның беренче абзацында «төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза алган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында.(http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И. Гозәеров